**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2020 №1383

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнар күләмен раслау турында» 2019 елның 12 февралендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләмнәренең һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә

юнәлтелә торган чыгымнарның план күрсәткечләрен раслау турында» 2009 елның 12 февралендәге 92 номерлы карарының 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә, әлеге карарның кушымтасы нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х. Хабибуллловага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
12 февралендәге 92 номерлы
карарына 3 нче кушымта (2020
елның 30 декаберендәге 1383
номерлы карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрнең һәм максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның 2021 елга тәкъдим ителә торган план күрсәткечләре**

| Учреждение исеме | Керемнәр күләме, мең сум | Хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнар күләме, мең сум |
|---|---|---|
| **Барлыгы** | **6375,0** | **255,0** |
| **МӘГАРИФ** | **4 331,0** | **-** |
| мәгариф учреждениеләрендә туклану өчен ата-аналар түләве | 3 891,0 | - |
| белем бирү хезмәтләре (укыту өчен ата-аналар взнослары һәм башкалар.) | 440,0 | - |
| **МӘДӘНИЯТ** | **344,0** | **255,0** |
| **Мәдәни-ял итү учреждениеләре** | **300,0** | **225,0** |
| билетлар сату (концертлар, спектакльләр, күргәзмәләр һ. б.), мәдәни-тамаша чаралары үткәрү, костюмнар, яктылык һәм тавыш җайланмалары, музыка уен кораллары прокаты, вакытлыча кулланылышка торак булмаган бина бирү һ. б. | 300,0 | 225,0 |
| **Музейлар** | **30,0** | **20,0** |
| музей хезмәтләре (лекцияләр, экскурсияләр һ. б.) | 30,0 | 20,0 |
| **Китапханә** | **14,0** | **10,0** |
| Башка хезмәтләр (Компьютер хезмәтләре, күчермә ясау, видео хезмәтләр һ. б.) | 14,0 | 10,0 |
| **СПОРТ** | **1700,0** | **-** |
| **Спорт комплексы** | **1700,0** | **-** |
| Спорт юнәлеше (бассейн, тренажер залы, бильярд, теннис, сауна-бассейн һ. б.), эшмәкәрлек эшчәнлеге (сәүдә, кафе, аренда, прокат, кунакханәләр, массаж һ. б. хезмәтләр) | 1700,0 | - |